КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 20 март г.Казань № 150

Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проекты составына керә торган «Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» федераль проекты кысаларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру чаралары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проекты составына керә торган «Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия рәвешендә бирелә торган акчаны тоту кагыйдәләрен (карарга теркәлә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгын Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проекты составына керә торган «Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия бирү өлешендә Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү федераль хезмәте белән хезмәттәшлек

итүне гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проекты составына керә торган «Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүне тәэмин итү өчен халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү һәм хезмәт базарының нәтиҗәлелеген арттыру» федераль проекты кысаларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру чаралары турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1264 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 20 март, 150 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проекты составына керә торган «Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия рәвешендә бирелә торган акчаны тоту кагыйдәләре

1. Әлеге Кагыйдәләр Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проекты составына керә торган «Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидия рәвешендә бирелә торган акчаны (алга таба – субсидия) тоту тәртибен билгели.

Халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыру «Демография» илкүләм проекты составына керә торган «Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» федераль проектына җәлеп ителгән Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте буенча кайбер дәүләт учреждениеләрендә гамәлгә ашырыла һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары эшчәнлеген оештыруга карата бердәм таләпләр (алга таба – шул ук эзлеклелектә модернизацияләү буенча проектлар гамәлгә ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре, бердәм таләпләр) кертүне күздә тота.

2. Субсидия Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы өчен Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә (алга таба – Казначылык) ачылган Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетына керә.

3. Субсидияне тоту әлеге Кагыйдәләрнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм субсидияне финанслауның иң чик күләмнәре турында Казначылыктан мәгълүмат алган көннән җиде эш көне эчендә агымдагы финанс елына субсидияне финанслауның иң чик күләмнәрен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – Министрлык) җиткерә.

5. Министрлык агымдагы финанс елына субсидияне финанслауның иң чик күләмнәре турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгыннан мәгълүмат

алган көннән җиде эш көне эчендә агымдагы финанс елына финанслауның иң чик күләмнәрен модернизацияләү буенча проектлар гамәлгә ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренә Министрлык тарафыннан билгеләнгән агымдагы финанс елына бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә җиткерә.

6. Әлеге Кагыйдәләрнең 5 пунктында күрсәтелгән субсидия модернизацияләү буенча проектлар гамәлгә ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан бердәм таләпләрне кертү өлешендә халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләренең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән түбәндәге чараларның берсен яки берничәсен финанслауга җибәрелә:

а) модернизацияләү буенча проектлар гамәлгә ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең биналарына һәм бүлмәләренә агымдагы һәм капиталь ремонт ясау;

б) уңайлылык дәрәҗәсен тәэмин итүне үз эченә ала торган модернизацияләү буенча проектлар гамәлгә ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре хезмәткәрләренең эш урыннарын җиһазландыру;

в) модернизацияләү буенча проектлар гамәлгә ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре бизәлешенең фирма стилен кертү, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында модернизацияләү буенча проектлар гамәлгә ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә күрсәтелә торган хезмәтләр һәм чрдәм чаралары турында гражданнарга һәм эш бирүчеләргә мәгълүмат бирү өчен билгеләнгән полиграфик продукция җитештерү; навигация чаралары, табличкалар һәм элмә такталар ясау һәм аларны урнаштыру, модернизацияләү буенча проектлар гамәлгә ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре хезмәткәрләрен униформа белән тәэмин итү;

г) сакчыл җитештерү принципларын һәм инструментларын кулланышка кертү, гражданнарның тормыш хәлләрен һәм эш бирүчеләрнең бизнес хәлләрен исәпкә алып, хезмәт күрсәтү процессларын оптимальләштерү, аларның технологик схемаларын эшләү һәм гамәлгә кертү;

д) Татарстан Республикасы территориясендә бердәм таләпләр кертүне һәм таратуны оештыру, шул исәптән модернизацияләү буенча проектлар гамәлгә ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре эшчәнлегендә кулланыла торган автоматлаштырылган мәгълүмат системаларын эшләү, кертү һәм аның эшләвен оештыру-методик яктан тәэмин итүне, модернизацияләү буенча проектлар гамәлгә ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан кулланыла торган, мәгълүматны саклау өлкәсендәге Россия Федерациясе законнары нигезендә сакланган элемтә каналларын булдыру һәм аларның эшен тәэмин итүне кертеп;

е) модернизацияләү проектлары гамәлгә ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүне тикшерүдә тоту һәм аларның сыйфатын бәяләү системасын формалаштыру.

7. Модернизацияләү буенча проектлар гамәлгә ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре, үзләренә билгеләнгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә һәм аларның счетына әлеге Кагыйдәләрнең 5 пунктында күрсәтелгән акча керүгә карап, дәүләт ихтыяҗлары һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә әлеге Кагыйдәләрнең 6 пунктында каралган чараларны тормышка ашыруны тәэмин итү максатларында төзелгән дәүләт

контрактлары (шартнамәләре) буенча товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) өчен түләүне гамәлгә ашыра.

8. Модернизацияләү буенча проектлар гамәлгә ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 11еннән дә соңга калмыйча, Министрлык тарафыннан расланган формалар буенча финанслашу максаты белән субсидия бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турындагы хисапны, субсидиядән файдалану нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турындагы хисапны Министрлыкка кертә.

Министрлыкка кертелә торган хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык модернизацияләү буенча проектлар гамәлгә ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренә йөкләнә.

9. Министрлык, модернизацияләү буенча проектлар гамәлгә ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү федераль хезмәтенең иҗтимагый финанслар белән идарә итү буенча «Электрон бюджет» дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасыннан файдаланып әзерләнә (формалаштырыла) һәм төзелә торган субсидия бирү турындагы килешүдә (алга таба – Субсидия бирү турындагы килешү) билгеләнгән субсидиядән файдалану нәтиҗәләренә ирешү өчен җавап бирә.

10. Министрлык Субсидия бирү турындагы килешүнең кушымталары нигезендәге формалар буенча Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү федераль хезмәтенә билгеләнгән срокларда хисаплар кертә.

11. Субсидиядән максатчан файдаланмау Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка тарта.

12. Хисап елыннан соң килә торган финанс елның 1 гыйнвары хәленә карата субсидиянең файдаланылмый калган өлеше Россия Федерациясенең бюджет законнары белән билгеләнгән таләпләр нигезендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

13. Субсидия бирү турындагы килешүдә каралган йөкләмәләр бозылган очракта, субсидияне федераль бюджетка кире кайтару Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү турында» 2014 ел, 30 сентябрь, 999 нчы карары белән расланган Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләрендә каралган тәртиптә һәм шартларда гамәлгә ашырыла.

14. Бу Кагыйдәләр нигезендә бирелгән акчаны максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык һәм модернизацияләү буенча проектлар гамәлгә ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.